КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 март г.Казань № 375

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларының исемен үзгәртү турында» 2021 ел, 6 сентябрь, 834 нче карарына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларының исемен үзгәртү турында» 2021 ел, 6 сентябрь, 834 нче карарына, аңа түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$1^1$. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

«Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Югары Отар балалар интернат йорты» дәүләт казна учреждениесе хезмәткәрләренең иң чик штат санын – 107,58 штат берәмлеге, «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Дербышки балалар интернат йорты» дәүләт казна учреждениесе хезмәткәрләренең иң чик штат санын – 247,15 штат берәмлеге күләмендә;

«Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Югары Отар балалар интернат йорты» дәүләт казна учреждениесенең койка фондын – 80 стационар койка-урын, «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Дербышки балалар интернат йорты» дәүләт казна учреждениесенең койка фондын – 210 стационар койка-урын күләмендә.».

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кайбер социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең койка фондына үзгәреш кертү турында» 2006 ел, 30 декабрь, 660 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларының койка фондын арттыру турында» 2012 ел, 15 ноябрь, 986 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең төрен үзгәртү юлы белән Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт крсәтү өлкәсендә дәүләт казна учреждениеләрен (акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларын) төзү турында» 2018 ел, 18 октябрь, 944 нче карарындагы 2 пунктының дүртенче һәм бишенче абзацлары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин